**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ*
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты
авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**22 август 2022 ел** **№ 15**

## Аерым норматив-хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советының «Арча муниципаль районы Кушлавыч авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген туктату турында» 2011 елның 6 декабрендәге 6 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кушлавыч авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип  танырга:

- «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кушлавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында» 24.02.2011 №1;
- « Кушлавыч авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен һәм исемлеген раслау турында» 31.08.2010 № 13;
-"Муниципаль хезмәткәрне коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе турында"22.12.2009 №4

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Утар-Аты  авыл җирлеге  башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева